# Аллаһның Сыйфатларыннан 13 Сыйфаты

Пәйгамбәр һәм Аллаһ илчесе Мөхәммәд (салләллаһу ‘аляйһи үә сәлләм): «Һәр мөселман ир-ат һәм хатын-кызы Ислам буенча белемнәргә омтылырга тиеш. Чыннан да, белемнәр – дөрес карашларның дәлиле. Ислам дине тәгълиматы кагыйдәләренә каршы килүче карашларга ия кеше мөселман була алмый.
Иман буенча белемнәрдән иң әһәмиятлесе – Аллаһ турындагы белемнәр.
Безне Яратучыга, Ул гына лаек булган иң бөек Сыйфатлар (Атрибутлар) хас. Аллаһның сыйфатлары мәңгелек һәм бернәрсәгә дә охшамаган. Аллаһ Аңа кәферләр (дингә ышанмаучылар) тарафыннан ягылган кимчелекләрдән чиста.
Аллаһның 13 Сыйфатын (Атрибутын) һәр мөкәлләф тә (Кыямәт көнендә җаваплылар) белергә тиеш, чөнки аларны белү һәм аларга ышанганлык күбесенчә мөселманның иманын билгели. Аллаһның бу 13 Сыйфаты хакында Изге Коръәндә дә сүзен-сүзгә яки мәгънәсе буенча искә алына.
1) Аллаһның барлыгы.
Кем Аллаһның барлыгын танымый, шул кәфер (дингә ышанмаучы). Хат язучыдан башка хат, төзүчедән башка корылма булмаган кебек, бу дөньяның барлыгын аны Яратучы, Барлыкка Китерүчедән башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Аның Исеме – Аллаһ (Барлыкка Китерүчегә пәйгамбәрләрнең соңгысы, Аллаһ илчесе Мөхәммәд (салләллаһу ‘аляйһи үә сәлләм) шулай мөрәҗәгать иткән).
2) Аллаһнының булуы башлангычсыз.
Аллаһдан башка һәр нәрсәнең дә (вакытның, урынның, күренеш нең һ.б. ның) башлангычы бар, чөнки алар яратылган.
3) Аллаһның булуы ахырсыз. Аллаһ мәңгелек.
Аллаһдан башка тагын кешеләр һәм женнәр җаннарының, шулай ук Кыямәт Көненнән соң кешеләр һәм женнәр бүленәчәк Җәннәт белән Җәһәннәмнең ахыры юк.
4) Аллаһ бер.
Аллаһ бердәнбер Яратучы. Ул Үзеннән кала бар нәрсәне дә яраткан (хәтта безнең ихтыярсыз башкарылган хәрәкәт һәм уйларыбызны да). Аңа тиңнәр булмаган, юк һәм булмаячак.
5) Аллаһның булуы – Үзеннән-Үзе, Ул беркемгә дә һәм бернәрсәгә дә мохтаҗ түгел.
Ә Аллаһ яралткан һәр җан иясе Аңа мохтаҗ. Аллаһның әлеге Сыйфатын белү (Ислам галимнәре җиткерүенчә) Аллаһ турында белемнәрнең иң әһәмиятлесен, ә бигрәк тә, Аллаһның образсыз һәм урынсыз булуын, үз эченә ала.
Әгәр берәр кем Аллаһ күктә, яисә бөтен төштә, яки инде тагын кайдадыр, дип уйласа, ул Исламнан тайпыл ган була һәм бу кешегә, ул элек мөселман булса, мөмкин кадәр тизрәк Исламны кабул итәргә кирәк (моны ничек эшләргә икәнлеген бу мәкалә ахырыннан укыгыз).

**Аллаһның урынсыз булуына дәлил**

Аллаһ бар нәрсәне дә барлыкка китергәнче, Үзе булдырган әйберләрнең берсенә дә, шул исәптән образ белән урынга да мохтаҗлык кичермәгән, чөнки әле боларның берсе дә булмаган. Образ белән урынны барлыкка ки тергәч тә, Аллаһ образга да, урынга да, һәм беркемгә дә, бернәрсәгә дә мохтаҗ булмавын дәвам итә. Шулай итеп, Аллаһ образсыз һәм урынсыз.
6) Яратылганнардан аермасы. Аллаһ бернәрсәгә дә һәм беркемгә дә охшамаган. Аллаһ – бар нәрсәне дә яратучы һәм Ул Үзе барлыкка китергән бернәрсәгә охшамаган һәм аларның берсе дә түгел.

Кайберәүләр Аллаһны «Яктылык», «Нур», «Бөек Акыл», «Изге Рух», «Суперкөч», «Абсолют» һ.б., диләр.

Бу – кәферләр (дингә ышанмаучылар) карашы. Бу кеше-ләргә без: «Аллаһ яктылыкны, нурны, акылны, көчне яратучы һәм Ул аларның берсе дә түгел», – дип җавап бирәбез. Ислам галимнәре әйтүенчә, кеше күз алдына китерергә мөмкин булган һәр нәрсәнең ахыры бар. Аллаһ моңа охшамаган.
Кеше күз алдына китерергә мөмкин булган бөтен нәрсә дә яратылган.
7)Аллаһ Зур Кодрәтле. Аллаһ бар нәрсәне дә булдыра. Аллаһ бу дөньяны яраткан, әтисез, әнисез балчыктан Адәм галәйһиссәламне (‘аляйһиссәләм), ә Адәмнең кабырга-сыннан Һаваны яраткан. Һәм Аллаһка әтисез Гайсәне (‘аляйһиссәләм) ярату авыр булмаган.
8)Аллаһның ихтыяры. Бернәрсә дә Аллаһ ихтыярына каршы башкарылмый. Аллаһ нәрсә теләсә, шул була, Аллаһ бар нәрсәне – яхшылыкны һәм начарлыкны да яраткан, әмма кешеләргә яхшылык эшләргә кушкан. Яхшылык – Аллаһтан, ә начарлык – шайтаннан, дип санаучылар ялгышалар, чөнки «ике яратучы» була алмый.
9)Аллаһ Тере. Әмма Аның яшәеше безнекенә охшамаган: без тән һәм җан белән яшибез – ә Аллаһ бернәрсәдә дә, беркемдә дә ихтыяҗ кичерми. Ал-аһының яшәеше мәңгелек.
10) Аллаһ Барысын Да Белүче.
Аллаһ нәрсә булган, бар һәм булачак – барысын да белә. Аның белеме – мәңгелек, ул үзгәрми дә, яңармый да.
11) Аллаһның ишетүе. Аллаһ бар нәрсәне дә ишетә. Аллаһның ишетүе безнекеннән аермалы. Аллаһга ишетү өчен ишету әгъзасы кирәкми. Аллаһның ишетүе мәңгелек.
12) Аллаһның күрүе.
Аллаһ Барысын Да Күрүче. Аллаһ күрә, әмма безнең кебек түгел. Аңа күрү өчен күрү әгъзасы кирәкми. Аллаһның күрүе мәңгелек.
13) Аллаһның сөйләме. Аллаһ сөйләшә, әмма без нең кебек түгел. Аллаһга сөйләшү өчен сөйләм әгъзасы кирәк түгел. Безнең сөйләмебез авазлар һәм паузалардан тора. Аллаһның сөйләме бернәрсәгә дә охшамаган. Ал лаһының сөйләме мәңгелек.

Кемнең бу юлларны укыганга кадәр карашлары монда язылган белемнәр белән туры килмәсә (ягъни киресенчә булса, мәсәлән, кем дә булса «Аллаһ – күктә» яки «Ал лаһы – рух, нур» һ.б., дип санаган булса), бу кешегә ки чекмәстән Исламны кабул итәргә кирәк.
Моның өчен, дөрес булмаган карашлардан баш тартып, Ислам кабул итү теләге белән гарәп телендә ике Ислам Шәһадәтенең сүзләрен яки нинди дә булса башка телдә аларның мәгънәсен әйтергә кирәк (мәсәлән, татар те лендә түбәндәге сүзләрне әйтәләр: «Мин Аллаһдан баш ка тәңре юклыгын беләм, таныйм һәм ышанам һәм мин Мөхәммәднең Аллаһ колы һәм Аның соңгы илчесе булуын беләм, таныйм һәм ышанам»),
Исламга мөмкин кадәр тизрәк кайтырга кирәк, чөнки кеше үлгәнче Ислам кабул итәргә өлгермәсә (ә безгә кан чан бу дөньядан китәсебез мәгълүм түгел), ул диннән тан пылучы булып үлә һәм үзенең ышанмаучанлыгы аркасында дөнья беткәч бу кеше бәхетсезләр рәтенә туры килеп, Җәһәннәмгә эләгә, аннан инде беркайчан да чыкмый, чөнки көфер (ышанмау) – аннан кечерәк бар гөнаһны да кичерә алган Аллаһ кичерми торган иң зур гөнаһ. Бөтен гомере буена мөселман үз динен сакларга һәм аны бозарга мөмкин булган һәр нәрсәдән сакларга тиеш.